**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ
СТАРОКАДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Советская, д.6, с.Старое Кадеево, 423117

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Совет урамы, 6 йорт, Иске Кади авылы, 423117

тел./факс (84396) 3-13-25 email: Skad.Cmn2@tatar.ru

№99 15.11.2018ел.

**Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 апрелендәге 81 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясы, «җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июлендәге 481 номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Уставы белән Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 апрелендәге 81 номерлы карары белән расланган Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләренең, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.«Иске Кади авыл җирлеге башлыгы өчен түләү» I бүлегендә 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Иске Кади авыл җирлеге башлыгына ай саен акчалата түләү түләнә. Күрсәтелгән затларның хезмәт өчен түләү чыгымнарының айлык акчалата түләү өлешендә күләме авыл җирлеге башлыгы өчен елына 6,72 айлык акчалата бүләкне тәшкил итә торган нормативтан артмаска тиеш"

3.Әлеге карарның гамәлдә булуын билгеләү 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Башлык,
Иске Кади авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе И.С.Мухутдинов